**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

13 ноябрь 2020 ел № 2

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлеге составына керуче Югары Чыршылы авылында 2021 елда үзара салым кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Югары Чыршылы авыл жирлеге составына керүче Югары Чыршылы торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Югары Чыршылы авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 нче төркем инвалидларыннан, вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнардан, көндезге уку йортлары студентларыннан тыш, 2021 елда 300 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә

- Югары Чыршылы авылында балалар өчен уен җиһазлары сатып алу һәм урнаштыру;
- Югары Чыршылы авылы зираты территориясен киртәләп алу өчен төзелеш материаллары сатып алу;
- оешма территорияләрен һәм юл буйларын чабу буенча эшләр өчен түләү ;
- Югары Чыршылы мәдәният йорты территориясендә төзелеш материаллары сатып алу һәм койма урнаштыру буенча эш өчен түләү;
- МТЗ-82.1 тракторы өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу;

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Югары Чыршылы авыл җирлеге Советының мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән,Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http: //pravo.tatarstan.ru., Сарман муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында http: //sarman.tatarstan.ru. кабул ителгәннән соң җиде көн эчендә бастырып чыгарырга.

Халык җыенында рәислек итүче
Сарман муниципаль районы
Югары Чыршылы авыл җирлеге башлыгы И.Н.Камалетдинов